ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТУРИЗМУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТУРИСТЛЫК БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

12.10.2017 Казан ш. № 173

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында аларны биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, аларны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында

"Коррупциягә каршы көрәш турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законны, "Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында" 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законны, Татарстан Республикасы Президентының "Аларны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары турында, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турында, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында" 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-701 номерлы Указын, Татарстан Республикасы Президентының "Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъвалык белдерүче гражданнар тарафыннан керемнәре, чыгымнары турында, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру турында" 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указын үтәү максатында б о е р ы к б и р ә м:

1. Кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында аларны биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, аларны

биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген (алга таба – Вазыйфалар исемлеге) расларга.

2. Кадрлар һәм юридик эш бүлегенә:

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында Вазыйфалар исемлегенә кертелгән вазыйфаларны биләгән дәүләт граждан хезмәткәрләренә аларны эштән куганда "Коррупциягә каршы көрәш турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясында каралган чикләмәләре, бурычлары һәм җаваплылыклары турында аңлатырга;

бу боерыкны Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре, Татарстан Республикасы Турислык буенча дәүләт комитетында Вазыйфалар исемлегенә кертелгән вазыйфаларны биләүче Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре игътибарына җиткерергә.

3. Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының "Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында аларны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары турында, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турында, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында" 2016 елның 12 декабрендәге 140 номерлы боерыгының көчен югалтуын танырга.

4. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Рәис С.Е. Иванов

Татарстан Республикасы
Туристлык буенча дәүләт
комитетының 12.10.2017
№ 173 боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында аларны биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, аларны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге

1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең иң югары вазыйфалар төркемендәге "җитәкчеләр" категориясе вазыйфалары:

рәис урынбасары.

2. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең төп вазыйфалар төркемендәге "җитәкчеләр" категориясе вазыйфалары:

туристлык эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу бүлеге башлыгы;

туристлык продуктын күрсәтү бүлеге башлыгы;

туристлык индустриясен үстерү бүлеге башлыгы;

дәүләт программаларын үстерү һәм тормышка ашыру бүлеге башлыгы;

кадрлар һәм юридик эш бүлеге башлыгы;

бухгалтерлык исәбе һәм дәүләт заказы бүлеге башлыгы.

3. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфалар төркемендәге "белгечләр" категориясе вазыйфалары:

туристлык эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу бүлегенең әйдәп баручы белгече;

дәүләт программаларын үстерү һәм тормышка ашыру бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

кадрлар һәм юридик эш бүлегенең әйдәп баручы консультанты.

4. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфалар төркемендәге "тәэмин итүче белгечләр" категориясе вазыйфалары:

бухгалтерлык исәбе һәм дәүләт заказы бүлегенең әйдәп баручы белгече.

5. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең өлкән вазыйфалар төркемендәге "тәэмин итүче белгечләр" категориясе вазыйфалары:

бухгалтерлык исәбе һәм дәүләт заказы бүлегенең 1 разрядлы өлкән белгече.